КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 декабрь г.Казань № 1191

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карары белән расланган 2021 елга дәүләт хезмәте күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1159 нчы; 2021 ел, 27 гыйнвар, 28 нче; 2021 ел, 25 февраль, 95 нче; 2021 ел, 26 май, 375 нче; 2021 ел, 28 июль, 662 нче; 2021 ел, 13 сентябрь, 867 нче; 2021 ел, 3 ноябрь, 1045 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2021 елга дәүләт хезмәте күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларына, 2 пунктның 2.4 пунктчасындагы «1,32» саннарын «1,20» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин